«Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең
җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләре буенча комиссия рәисе

______________________И.Ф. Рәхимов

№ 13 2020 елның 29 декабре

Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү

**БӘЯЛӘМӘСЕ**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгының «Ачык тыңлауларны билгеләү турында» 2020 елның 19 ноябрендәге 29 номерлы карары белән билгеләнгән ачык тыңлаулар 2020 елның 28 декабрендә 11.00 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.

2020 елның 29 декабрендәге 13 номерлы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү беркетмәсе.

**Ачык тыңлаулар предметы:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы мөрәҗәгате буенча, Ж-1 «Индивидуаль торак йортлар белән төзелеш зонасы» территориаль төзелеш зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Фрунзе ур., 117 нче йорт чикләрендәге территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54:160:102:60 булган, 3064,7 кв.м мәйданлы җир кишәрлеге, Ж-2 «Урта катлы торак йортлар төзү зонасы» зонасына кертү өлешендә, кисәтүләр булмады.

**Карар иттеләр:**

1. Ж-1 «Индивидуаль торак йортлар белән төзелеш зонасы» территориаль төзелеш зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Фрунзе ур., 117 нче йорт чикләрендәге территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54:160:102:60 булган, 3064,7 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген, Ж-2 «Урта катлы торак йортлар төзү зонасы» зонасына кертү өлешендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларны узган дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында проектны хупларга һәм аны раслау өчен депутатлар Советына җибәрергә.

3. Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия сәркатибе: __________________Бибишев М.Р.